**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

25.03.2024 ел № 4

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 14 мартындагы «2023 елның 26 октябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 3 санлы, 2023 елның 26 октябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 3/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында»гы 10 санлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пунктында узган гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «2023 елның 26 октябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 3 санлы, 2023 елның 26 октябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 3/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташкичү торак пунктында су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм торак пунктта яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итү (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар, транспорт хезмәтләре сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев